ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.05.2022 г. Казань № 59-12/кс2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын су транспортлауга һәм агып җыела торган суларны транспортлауга 2022 елга тарифлар билгеләү турында» 08.12.2021 № 462-129/кс-2021 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны җайга салу кагыйдәләренең 8 пункты, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2022 елның 25 маендагы 12-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын су транспортлауга һәм агып җыела торган суларны транспортлауга 2022 елга тарифлар билгеләү турында» 08.12.2021 № 462-129/кс-2021 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «салкын су транспортлауга һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «салкын су транспортлауга һәм», «салкын су белән тәэмин итү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «салкын су белән тәэмин итү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.12.2021 № 462-129/кс-2021
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
25.05.2022 №59-12/кс-2022
карары редакциясендә)

Агып җыела торган суларны агызуны гамәлгә ашыручы «РСК» ҖЧҖ өчен 2022 елга агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | |
| 1 | «РСК» ҖЧҖ | | |
| 1.1 | «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге кулланучылары (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 1,64 | 1,64 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге